***<u>Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәренең</u>***

***<u>1 нче Лицее" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.</u>***

# Тикшеренү эше

# Тема: “Тау ягының яшь йолдызы”

Башкарды: Гибадуллина Лиана, 8 сыйныф.1нче Лицей

Җитәкче: Закирова Ләйсән Амдатовна.Татар теле һәм әдәбияты укытучысы

2020 ел

Яшел Үзән

**Эчтәлек**


1. Кереш өлеше 2
2. Төп өлеш 5
3. Йомгаклау 8
4. Кулланылган әдәбият 9

## Кереш

Туган як... Һәркемгә: олысына-кечесенә, яшенә-картына, баласына, яшүсмеренә, гомумән,- һәммәсенә дә туган як, туган төбәк, яланаяк чирәмендә йөргән, болынында аунап үскән, тәмле чишмә суларын эчкән һәм сине олы тормыш сукмагына хәер-фатихасын биреп озаткан туган авылы якын һәм кадерле.

Һәрбер язучы үзенең әсәрләрендә, шагыйрьләр шигъри юлларында, рәссамнарның картиналарында туган як, туган якның гореф-гадәтләре сине тәрбияли, күңеләңне нечкәртә, кешелекле, мәрхәмәтле булырга өнди.

Дөрестән дә, күпме сәләтле кешеләр: бүгенге көндә зур урында эшләүчеләр, галимнәр, фән эшлекләре, спорт алдынгылары, авыл җирлегендә тәрбияләнеп кешелеклелек орлыкларын туган төбәгендә сеңдереп, катлаулы тормыш юлына аяк басканнар.

Уйлап карасаң, гади авылдан, балаларның сәләтләрен үстерү юнәлешендә әллә ни әйтүле шартлар булмаган дәвердә дә, каян килгән бу талант иясе дип, шаккатып сөйләрлек кешеләр минем әбиемнең туган төбәгемдә, Буа районы, Кайбыч авылында да бар бит. Алар белән чын күңелдән горурлану хисләре кичерәсең, аларга кызыгып карыйсың һәм уйлыйсың:  миндә киләчәктә шул талант ияләре дәрәҗәсенә күтәрелә алырмынмы , дип уйлап куясың.

Нинди генә талант ияләре чыкмаган бу авылдан:

- Идрисов Газимҗан Җиһанша улы озак еллар буе ветеринария академиясенең ректоры, профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхес;
- Күп җырлар авторы, җырчы, баянчы, бүгенге көндә дә үз авылында яшәп иҗат итүче Мортазин Фирзәр Солтан улы;
- Хәмидуллин Ринат Насратулла улы – “Вираж” чикләнгән җәмгыятенең генераль директор урынбасары;
- Гарипов Марат Хәсип улы – нефть корпорациясенең план бүлеге директоры;

-Әхмәтова Гөлфирә Әбзал кызы – 62 яшенә кадәр балалар тәрбияләүгә зур өлеш керткән һәм бүгенгесе көндә шигырьләр җыентыгы авторы.

Саный китсәң, кулыңдагы бармаклар саны җитмәс.

Гомерләрен күктә атылган йолдыз белән чагыштырырдай, үз гомерләрен аямыйча хезмәт иткән һәм яшь булуга карамастан, зур үрләргә ирешкән, безнең арабыздан мәңгелеккә киткән кешеләр арасыннан – Гарипов Фәиз Кәрим улын әйтеп китү кирәк.

1947 нче елда туып, илебезнең иң авыр елларында да укуга булган омтылышын югалтмыйча, Саратовта высший командно- инженерный институтны тәмамлап, арабыздан киткәнче, хәрби кеше булып, полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхес ул. Тикмәгә генә, 23 нче февраль көнне, мәдәният йортында үткәрелгән чарада, Ватан сагында башларын салган кешеләр хөрмәтенә бер минут тынлык игълан иткәндә, шушы кешенең дә исем, фамилиясе яңгырый. Өстә санап киткән кешеләрне бездә беләләр, хөрмәтлиләр, тирә-як төбәкләрендә дә исемнәре билгеле, күбесенең даны Буа районына гына түгел, Татарстанга яңгырый.

Чын күңелемнән рәхмәт аларга!

## Төп өлеше

Иҗат эшемнең төп максатына әйләнеп кайтасым килә. Ә бит бар шундый кешеләр: тыныч кына, үзләренә игътибарны юнәлтмичә, үзләренең күңелләренә хуш килгән эш белән шөгыльләнүчеләр.

Укытучы апа конференциянең дүрт юнәлеше белән таныштырып чыккач, иң соңгы юнәлеш темасына тукталырга булдым. Теманы сайладым һәм туган авылыбыздагы конференция тематикасына туры килерлек күренекле шәхесләребезне барларга керештем. Бу эшкә этием һәм әниемне дә җәлеп иттем. Ээшемә кирәкле мәгълүмәтләр туплап, фәнни-гамәли эшемнең максатлары һәм бурычларын билгеләдем.

***Иҗади эшемнең максатлары һәм бурычлары***

- Туган туфракта тәрбияләнеп зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр белән таныштыру;
- Үзебезнең авыл җирлегендә туып үскән, каләм тибрәтүче, хикәяләр авторы – Закирова Лилия Хатип кызы белән таныштыру һәм , күпмедер дәрәҗәдә, аудитория алдында аның исемен һәм китабын таныту;
- Хикәяләренең тематикасын анализлау.

Әйе, чынлап тә, гади авылда тәрбияләнеп, 26 хикәя авторын Буа төбәгендә белергә тиешләр дип саныйм.

Дөрестән дә, табигать тарафыннан салынган сәләтләр һәр кешедә бердәй булмый. Кайберәүләр, инде мәктәптә укыганда ук, рәсемгә осталыгы, артистлар дәрәҗәсендә җырлавы,шагыйрьләр игътибарын алырлык шигырьләр язуы белән шаккатыра. Еллар уза. Шундыйларның берсе чын талант иясе буларак бәяләнә, икенчесен илдә дә белмиләр, авылда да оныталар. Шул ук вакытта күзгә дә әллә ни чалынмаган өченче берәү, котелмәгән яклары белән ачылып китеп, хезмәтендә танылa һәм зур дәрәҗәләргә ирешә.

Сәбәп нәрсәдә? Минем уйлавымча, кешеләргә табигатьтән бирелгән сәләт кенә җитмидер. Әгәр тиешле тырышлык куймасаң, шул сәләтеңне ачу

юнәлешендә көч түкмәсәң, син барыбер мөмкинлекләрең зурлыгында үзеңне күрсәтә алмаячаксың.

Закирова Лилия Хатип кызы 1987 елның 21 июлендә Буа районы Кайбыч авылында төпчек бала булып дөньяга килә. Әнисе истәлекләреннән: “ Кечкенәдән үк башка кыз туганнарыннан аерылып тора иде. Һәрбер төскә, һәрбер яңалыкка, үзгәрешкә ихлас сокланып карый иде. Күбесенчә ялгыз йөри иде. Һәрнәрсәне тиз отып алучан булды.”



Балалар бакчасында йөргәндә үк, тиз истә калдыруы белән, башка балалардан бик нык аерылып торган. Балалар бакчасы тәрбиячесе апа истәлекләреннән: “ Төрле чаралар үткәргәндә, Лилия безнең иң беренче ярдәмчебез иде. Оста җырлый да, бии дә, ә инде шигырь ятлауга килгәндә, зур күләмле шигырьләрне икенче көнгә яттан сөйли иде. Хәтта иптәшләренең шигырьләрен, әгәр алар әйтә алмыйча торсалар, сөйләп бирә иде. Гаҗәеп сәләтле кыз иде.”

Башлангыч сыйныфларда гел “5” ле билгеләренә генә укый. Беренче укытучысы истәлекләреннән: “ Барлык фәннәрне дә ярата, ләкин туган тел,

татар теле фәннәрен аеруча якын итә иде. Яттан сөйләү – Лилия өчен иң җиңеле иде.”

Башлангычта укыганда, күңелендә туган хисләрне, үзе дә сизмичә, кәгазь битләренә төшерә һәм шигырь юллары туа. Әлбәттә, шигырь юллары үзе өчен генә язылып, беркемгәдә укылмыйча, беркайда да басылмыйча кала. Сыйныфташларыннан, укытучылардан, хәтта әнисеннән, туганнарыннан яшереп ничә шигырь генә тумагандыр кыз күңелендә.!? Кызганычка каршы, шигырьләре сакланмаган. Лилия апа аларны миңа табып күрсәтә алмады.

Урта сыйныфларда укыганда, мәктәп тормышының үзәгендә кайный. 8 нче сыйныфта беренче хикәясе барлыкка килә.Хикәянең исеме “ Алдау көне” дип атала. Бу иҗат җимешен татар теле һәм әдәбияты укытучысына күрсәтеп, беренче фатихасын ала.

Мәктәпне гел “5” билгеләренә генә тәмамлап, кая барырга дигән сорау белән борчылмыйча, Казан дәүдәт университетының татар теле әдәбияты бүлегенә укырга керә.

Лилия апаны Казан каласында үзгә тормыш, яңа ачышлар көтә. Иҗат чишмәсе киңәйгәннән-киңәя. Яшь каләм тибрәтүчеләр түгәрәгенә языла һәм аның сәләтен профессор апалар күреп ала. Язу серләренә өйрәнеп, 26 хикәядән торган “Яшерен мәхәббәт”дип исемләнгән җыентыгы, “Идел-Пресс”полиграфия-нәшрият комплексында 2007 елда басылып, дөнья күрә.

Лилия апа өчен иң шатлыклы көн, мөгаен, исе дә кибеп бетмәгән, табадан гына төшкән китабын кулга алган көн булгандыр, минемчә. Ничек инде шатланмыйсың? Синең иҗат җимешең, синең уйларың, хисләрең, төн йокламый язган хикәяләрең, эти-әнидән, туганнардан кала, иң кадерлеседер, мөгаен.


Әйтеп киткәнемчә, “Яшерен мәхәббәт” дип исемләгән китабында 26 хикәя тупланган. Лилия апа миңа үзенең китабын бүләк итте һәм зур кызыксыну белән укып чыктым. Эчтәлеге гади, ләкин һәрберсендә нинди дә булса тәрбияви якка юнәлдерелгән мәсьәләләр күтәрелгән. Кыска күләмле хикәяләр язу җиңелләрдән түгелдер дип уйлыйм, чөнки әйтәсе килгән фикерне кечкенә күләмле әсәрдә чагылдыру – катлаулы эшләрнең берседер. Барлык

хикәяләре дә яшүсмерләргә, балаларга, алар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, хезмәт, тәрбия, шәфкатьлелек темаларына багышлана.

**Йомгаклау**

Лилия Закирова иҗаты белән таныштыруны, китабын презентацияләүне максат итеп куйдым һәм максатыма ирештем дип уйлыйм.

Чөнки минем бу хезмәтемнән соң ,Лилия апаның иҗаты белән кызыксынучылар саны артыр .



## Кулланылган әдәбият


1. Лилия Закирова “Яшерен мәхәббәт”, Татарстан китап нәшрияты, 2007 ел.
2. Рифә Рахман “Татар телендә 100 сочинение”, “Раннур” нәшрияты, 2001 ел.

“